# "БУ СМАРТ-МӘКТӘП — БАШКОРТСТАННЫҢ ЙӨЗЕ!"

(⇨ Башы 1нче биттә).

— Яңа калкып чыккан йортлар арасында барлык таләпләргә туры килгән заманча мәктәпнең төзелүе — тотрыклы үсештә булган Башкортстанның йөзе! Бу — илдә булган смарт-мәктәпнең иң чагу мисалы. Президент Владимир Путин тарафыннан киләчәк буынга белем һәм тәрбия бирүгә зур игътибар бүленә. "Мәгариф" гомумдәүләт проектын тормышка ашыру максатында илдә күләмле эшләр башкарыла. Әлеге мәктәп — ил башлыгы куйган бурычны төгәл үтәүнең ачык мисалы,— диде, тантананы ачып, Игорь Комаров.

Башкортстан Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров, укытучыларны һәм укучыларны яңа уку елы башлану белән котлап, мондый мәктәптә укыту һәм белем алу күпләрнең хыялы булуын ассызыклады.

— Әлегә бу уку йортының матурлыгы тышыннан гына күренә. Ә киләчәктә ул көчле педагогик коллективы булган, тирән белемле укучылар әзерләүче мәктәп булачак, — диде Радий Фәрит улы.

Республика җитәкчесе билгеләвенчә, быел 21 мәктәп һәм 21 балалар бакчасы төзү планлаштырылган. Яңа уку елы башыннан өр-яңа 11 мәктәп һәм 5 балалар бакчасы ишекләрен ача. Алар барысы да үсеш өчен уникаль мөмкинлек бирүче "Мәгариф" гомумдәүләт проектларына ярашлы төзелә.

Әлбәттә, мәктәпнең ачылуы өчен иң сөенгәне балалар һәм әти-әниләр булды.

— Без бу мәктәп ачылуны түземсезлек белән көттек. Белем учагы безгә бик ошый. Укытуның төрле телләрдә алып барылуы балаларыбыз өчен киләчәктә зур мөмкинлекләр ачар дип ышанабыз, — ди беренче сыйныфка баручы Тимурның әнисе Рәмилә Хәйбрахманова.

Шул ук көнне Радий Хәбиров һәм Игорь Комаров, **Уфаның 105нче гимназиясе**ндә булып, укучыларны, аларның ата-аналарын һәм педагогларны яңа уку елы башлану белән котладылар.

Радий Хәбиров укытучыларга үсеп килүче буын белән эшләүдә һөнәри осталыклары өчен рәхмәт белдерде һәм республика мәгариф тармагына ярдәм күрсәтүен дәвам итәчәген белдерде.

– Без мәгариф үсешенә җитди игътибар бүләбез. Яңа мәктәпләр төзиячәкбез, аларга заманча җиһазлар сатып алачакбыз, заманча тенденцияләр рухында үсәчәкбез, – диде Радий Хәбиров.

Игорь Комаров һәм Радий Хәбиров Белем көненә багышланган тантаналы линейкада катнаштылар, сыйныфларда һәм мәктәп музеенда булдылар, укучылар белән аралаштылар.

**Юлия ТӨХБӘТУЛЛИНА.**

# ХАЛЫК МӘНФӘГАТЕНДӘ ВАК МӘСЬӘЛӘЛӘР БУЛМЫЙ!

(⇨ Башы 1нче биттә).

Республика җитәкчесе **"Башкортстан ихаталары"** программасын тормышка ашыру барышы белән Салават Юлаев урамындагы күпфатирлы алты йортның ишегалды территориясен караганда танышты.

Арытаба республика җитәкчесе **шәһәр педагогларының август киңәшмәсендә** катнашты. Радий Хәбиров чарада катнашучыларны яңа уку елы башлану белән котлады. Мәгариф өлкәсенең иң алдынгы хезмәткәрләренә – Башкортстанның дәүләт бүләкләре, ә тармак ветераннарына республика төзелүнең 100 еллыгына юбилей медальләре тапшырылды.

**"Салаватнефтехимпроект" институты**нда Радий Хәбиров сәнәгать модельләштерү технологияләре белән танышты. Оешма нефть эшкәртү һәм нефть химиясенең яңа төзелүче һәм реконструкцияләнүче производстволарын проектлый.

Арытаба төбәк җитәкчесенең эш сәфәре **Мәләвез районы** буенча дәвам итте. Район үзәгендә ул подъездларны ремонтлау программасы барышы белән танышты, урындагы халык белән аралашты.

**"Мәләвез сөт-консерва комбинаты"** җәмгыятендә Радий Хәбиров балалар туклануы өчен коры сөт продуктлары җитештерү буенча өстенлекле инвестиция проектын тормышка ашыру белән танышты. Ул җитештерү куәте арттырылуын хуплады һәм республиканың аларга ярдәм итәргә әзер булуын белдерде.

Радий Хабиров, шулай ук, **"Тулпар" ат-спорт комплексында** булды һәм район башлыгы белән комплекс җитәкчесен "Тулпар"ны модернизацияләү буенча фикер алышу өчен чакырды.

31 августта Республика җитәкчесе Радий Хәбиров **Кырмыскалы районында** легендар 112нче Башкорт кавалерия дивизиясе командиры Миңнегали Шәйморатовның 120 еллыгына багышланган бәйрәм чараларында катнашты. Ул Кырмыскалы районының Шәйморат авылында атаклы комдив һәйкәленә чәчәкләр салды.

Бәйрәм кунаклары һәм район халкы Миңнегали Шәйморатовның тормышын, легендар дивизиянең ничек барлыкка килүен һәм фронтка китүен чагылдыручы театрлаштырылган тамаша карады.

– Миңнегали Шәйморатов – башкорт халкының уникаль улы, уникаль кеше, легендар комдив, әмма, кызганычка каршы, бик фаҗигале язмышлы кеше. Без аны һәрвакыт истә тотачакбыз, халкы аны онытмасын, аның белән горурлансын өчен барысын да эшләячәкбез, аның истәлеген мәңгеләштерү өчен барлык чараларны да күрәчәкбез, — диде Радий Хәбиров.

1 сентябрьдә исә төбәк башлыгы **Уфа шәһәре** буйлап йөрде һәм 1 ноябрьгә уфалыларга "Первомайский" паркында һәм "Биюче торналар" фонтаны янында ял итү өчен заманча уңайлы урыннар булдырылачагын вәгъдә итте. Ул әлеге урыннарны Уфа мэры Өлфәт Мостафин белән карап чыкты.

Төбәк җитәкчесе **Орджоникидзе районы**нда "Яшь имәннәр" скверында да булды. Монда шәһәрнең визит карточкаларының берсе – "Биюче торналар" фонтаны ачылачак. Шәһәр халкы һәм кунаклары өчен монда сукмаклар, эскәмияләр һәм кече архитектура сыннары, җәмәгать туклануы зонасы оештырылачак.

Арытаба Радий Хәбиров **"Минем яраткан шәһәрем" һәм "Есть!" фестивальләре**ндә катнашты. Ул республика башкаласында беренче тапкыр уза һәм гаилә бәйрәме төрендә оештырылган. Фестиваль мәйданчыгы итеп Ленин урамы сайланды, ул бер көнгә җәяүлеләр зонасына әверелде. Чараның кунаклары өчен берничә тематик юнәлеш эшләде.

Төбәк җитәкчесе фестиваль мәйданчыкларының төрлелеген, осталарның һәм артистларның эш дәрәҗәсен бәяләде. Фестивальне оештыручылар фикеренчә, "Минем яраткан шәһәрем" – уфалыларның мәдәни-күңел ачу программасына гына түгел, ә туризм үсешенә, шәһәр һәм республика абруен арттыруга да зур өлеш кертә.

Радий Хәбиров, шулай ук, Кәрван-сарай каршындагы мәйданда Уфа рестораннарының "Есть!" фестивалендә булды.

**Үз хәбәрчебез.**

# ПУТИН БЕЗНЕ ЮККА МАКТАМЫЙ!

## Бер атна эчендә генә дә Башкортстанда берничә дистә миллиард сумлык инвестиция проектларына башлангыч бирелде

БЕЗНЕҢ КАРАШКА

**Соңгы чорда Башкортстанның халык хуҗалыгы барлык өлкәләрдә дә уңай якка җитди үзгәрешләр кичерә. Моны республикада яшәүчеләр генә түгел, ил җитәкчеләре дә билгели. Аерым алганда, Русия Президенты Владимир Путин узган атнада Башкортстан Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров белән очрашуда республиканың беренче яртыеллыктагы эшчәнлек йомгаклары белән танышканнан соң, аларны "бик яхшы" дип бәяләде.**

Атап әйткәндә, Радий Фәрит улы очрашуда ил җитәкчесенә җиткерүенчә, беренче яртыеллыкта республикада сәнәгать җитештерүе индексы 104,5 процент булган. Төзелеш тармагында үсеш 9 процент белән билгеләнгән. Авыл хуҗалыгы тармагы 100 процентка эшләгән. Предприятиеләрнең керемнәре һәм нәтиҗәлелеге сизелерлек артуга бәйле, беренче яртыеллыкта төбәктә уртача хезмәт хакы 35 мең 400 сумга җиткән. Ә иң зур үсеш исә инвестицияләр өлкәсендә күзәтелә.

– Төп капиталга инвестицияләр күләме 113,6 процент тәшкил итте. Былтыр ул – 92, аннан алдагы елда – 90, 2016 елда 102 процент иде. Икътисадка инвестицияләр җәлеп итү – безнең эшчәнлектә өстенлекле юнәлеш. Бу юнәлештә күрелүче колачлы чаралар нәтиҗәсендә хәзер төбәккә чит ил инвесторлары да агыла башлады. Әйтик, күптән түгел бездә Франциянең эре компаниясе йомшак сырлар җитештерү буенча завод төзи башлады, – диде бу хакта Президентка сөйләгәндә Радий Хәбиров.

– Бу бик яхшы, – диде, үз чиратында, Владимир Путин һәм төбәк җитәкчелеге алдында эшне алга таба да шушы югарылыкта алып бару бурычы куйды.

Хәер, соңгы ун айда Башкортстанда бу юнәлештә эшнең туктап түгел, бер генә мизгелгә акрынаеп торганы да юк, дисәк тә һич арттыру булмастыр. Әйтик, ил Президенты Владимир Путин белән очрашуның икенче көнендә үк **Башкортстан җитәкчесе Радий Хәбиров Республика йортында Израиль дәүләтенең Русиядәге Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле Илчесе Гарри Коренны кабул итте.** Әлеге очрашуда да сүз, нигездә, ике арада сәүдә-икътисади хезмәттәшлекне ныгыту, төбәккә Израильдән инвестицияләр җәлеп итү мәсьәләләре турында барды. Аерым алганда, "Сочи-2019" Русия инвестиция форумында Израильнең LR Group җәмгыяте белән төзелгән ниятләр турында килешүне тормышка ашыру мәсьәләләре тикшерелде. Биредә сүз Кушнаренко районында 7000 башка исәпләнгән сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексын төзү турында бара. Израиль ягы аның төзелешенә 10 миллиард сум инвестиция салырга ниятли. Әлеге очрашу барышында Гарри Корен республика җитәкчелегенә проектны хуплаганы өчен рәхмәт белдерде һәм аның уңышлы гамәлгә ашырылачагына ышандырды.

Шул ук көнне республика җитәкчесе Радий Хәбиров рәислегендә Хөкүмәттә үткән **"Инвестиция сәгате"** дә бу юнәлештә анык карарлар белән билгеләнде.

> *Үзәк яткылыгын файдалана башлаганнан соң еллык руда җитештерү күләме – 4,3 миллион тоннага, хезмәткәрләр саны 1400 кешегә җитәчәк. Шулай ук, әлеге территориядә яңа тау баектыру фабрикасы төзү дә күздә тотыла. Якынча исәпләүләр буенча, яңа яткылыкта запаслар 44 елга җитәчәк.*

Анда республика Хөкүмәте һәм "Патриот" ит эшкәртү комбинаты арасында Ишембай районында оештырылган махсус икътисади зонада ит консервалары җитештерү заводы төзү турында килешүгә кул куелды. Бүгенге көнгә бизнес-план тулысынча әзер, төзелешкә техник бирем формалаштырыла. Планлаштырылган инвестицияләр күләме 750 миллион сум тәшкил итәчәк.

29 августта исә Башкортстан Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров һәм Урал тау-металлургия компаниясенең генеральный директоры Андрей Козицын **Хәйбулла районында Подольск бакыр-цинк яткылыгын эшкәртүгә һәм яңа җир асты рудниగы төзелешенә старт бирделәр.** Аның нигезенә тәүге ташны салу тантанасында билгеләнүенчә, ул илдә бу төр иң эре рудникларның берсе булачак һәм Урал тау-металлургия компаниясе составындагы төп өч чимал базасының берсен тәшкил итәчәк.

– Бүген – безнең республика өчен бик әһәмиятле көн. Русия Федерациясендә иң эре яткылыкларның берсен эшкәртү башлана, ул дистә елларга сәнәгатьне тауруда чималы белән тәэмин итәчәк. Безнең өчен объектның нәкъ республикада төзелүе мөһим, чөнки бу яңа эш урыннары, инвестицияләр, Хәйбулла районының һәм гомум Башкортстанның социаль үсеше дигән сүз, – диде шушы уңайдан оештырылган тантанадагы чыгышында республика җитәкчесе Радий Хәбиров.

Әйтергә кирәк, Хәйбулла районында әлеге инвестиция проектын тормышка ашыру буенча ниятләр турында килешүгә җәй башында үткән "Урал аръягы" Бөтенрусия инвестиция сабантуенда кул куелган иде. Әлеге төзелешкә якынча 50 миллиард сум инвестиция салыначак дип күзаллана.

Объект ике этапта файдалануга тапшырылачак. Беренче чираттагы Төньяк яткылыгын 2025 елда гамәлгә кертү һәм аны биш ел дәвамында эшкәртү күзаллана. Тәүге этапта елына 1 миллион тонна руда чыгарылачак, 600 кеше эшкә җәлеп ителәчәк. Икенче чират 2032 елда эшкә кушылачак. Үзәк яткылыгын файдалана башлаганнан соң еллык руда җитештерү күләме – 4,3 миллион тоннага, хезмәткәрләр саны 1400 кешегә җитәчәк. Шулай ук, әлеге территориядә яңа тау баектыру фабрикасы төзү дә күздә тотыла. Якынча исәпләүләр буенча, яңа яткылыкта запаслар 44 елга җитәчәк.

30 августта исә Башкортстан җитәкчесе Радий Хәбиров **"Газпром нефтехим Салават" җәмгыятендә производствоны модернизацияләү** нәтиҗәләре һәм инвестиция программасын тормышка ашыру барышы белән танышты. Башкарылган эш һәм салынган күләмле инвестицияләр нәтиҗәсендә бүген завод иң заманча һәм экологик яктан иң хәвефсез продукция җитештерүгә күчте дияргә мөмкин. Мәсәлән, соңгы елларда иң эре инвестиция программаларының берсен тормышка ашыру нәтиҗәсендә биредә бүген Русиядә иң эре акрил кислотасы һәм бутилакрилат җитештерүче завод төзелгән. Ул елына 80ешәр мең тонна акрил кислотасы һәм бутилакрилат һәм 35 тонна боз акрил кислотасы җитештерү куәтенә ия.

Радий Хәбиров караган **"Мономер" заводы да** модернизацияләнгәннән соң 355 тонна этилен һәм 160 тонна пропилен җитештерү куәтенә чыккан.

Әлеге вакытта исә предприятиедә барган иң зур төзелеш – каталитик крекинг комплексы. Аны 2020 елда файдалануга тапшыру күздә тотыла. Яңа производствоның җитештерү куәте 1,1 миллион тонна продукция булачак.

Йомгаклап нәрсә әйтергә була? Республика җитәкчелеге колачлы инвестиция эшчәнлеге алып бару нәтиҗәсендә, күренүенчә, бер атна эчендә генә дә берничә дистә миллиард сумлык инвестиция проектларына башлангыч бирелде яисә эшкә кушылды. Шунлыктан, ил Президенты Владимир Путинның бу юнәлештә Башкортстанда алып барылган эшчәнлеккә шундый югары бәһа бирүе табигый. Иң мөһиме – алга таба да, нәкъ Президент кушканча, темпларны төшермәскә, эшне шушы югарылыкта алып барырга. Ә моның өчен бездән – республика халкыннан да – Башкортстан җитәкчелегенә гомум төбәк мәнфәгатендәге әлеге мөһим башлангычларында һәрдаим терәк-таяныч булуыбыз, яхшылыкка яхшылык белән җавап бирүебез сорала.

**Илдар ФАЗЛЕТДИНОВ.**

Издательство "Кызыл таң" — филиал ГУП РБ Издательский дом "Республика Башкортостан". Учредители республиканской общественно-политической газеты "Кызыл таң" — Государственное собрание — Курултай, Правительство Республики Башкортостан. Издается с 1 марта 1918 года. Выходит во вторник, четверг и пятницу на татарском языке.

Баш мөхәррир
Фаил Камил улы
ФӘТХЕТДИНОВ.
Мөхәрририят:
**Илдар Фазлетдинов** (җаваплы секретарь), **Фәнис Гәрәев, Резеда Нуртдинова, Рәфис Сәяхов**, **Олег Төхвәтуллин** (баш мөхәррир урынбасарлары), **Фәрит Фаткуллин.**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
450079, БР, Уфа, Октябрьнең 50 еллыгы урамы,13, 6нчы кат.
Адрес редакции и издателя:
450079, РБ, Уфа,
ул. 50-летия Октября,13,
6-й этаж.
kyzyltan@mail.ru

Гәзит Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәттә 2008 елның 24 сентябрендә теркәлде.
Теркәлү саны — ПИ №ФС 77-33268
Күләме – 2 басма табак
Гомум тиражы — 4773 данә
Заказ № 1432.

Гәзит "Кызыл таң" нәшриятының компьютер цехында җыелды һәм Нефтекама матбугат йорты типографиясендә басылды:
452680, БР, Нефтекама шәһәре,
Березовка шоссесы, 4А,
тел. (8-34783) 7-07-57.
Газета отпечатана в типографии Нефтекамского дома печати.
452680, РБ, г. Нефтекамск,
Березовское шоссе,4А,
тел. (8-34783) 7-07-57.

Телефоннар:

| | |
|---|---|
| Кабул итү бүлмәсе — | 272-13-61 |
| баш мөхәррир урынбасарлары — | 272-97-71; 273-50-56 |
| җаваплы секретарь — | 272-74-05 |
| Бүлекләр: | |
| сәясәт, икътисад һәм милли проблемалар — | 272-58-40 |
| әдәбият һәм сәнгать — | 272-35-22 |
| авыл тормышы һәм үз хәбәрчеләр челтәре — | 273-46-19 |
| яңалыклар — | 272-75-68 |
| хатлар һәм социаль мәсьәләләр — | 272-82-07 |
| рәссам — | 272-75-21 |
| реклама — | 272-62-27 |
| маркетинг — | 272-35-70 |
| бухгалтерия — | 273-43-43 |
| тәрҗемәчеләр — | 272-74-52 |
| "Әллүки" журналы — | 272-62-19 |
| "Тулпар" журналы — | 272-67-48 |

Факс — 273-88-01, 272-62-27
Үз хәбәрчеләребез:

| | |
|---|---|
| Октябрьский, Бүздәк, Әлшәй, Благовар | 8-937-30-24-087 |
| Борай, Кушнаренко, Дүртөйле | 8-917-80-37-750 |
| Илеш, Бакалы, Шаран | 8-937-49-35-735 |

*Гәзит чыгышларына карата килгән хатларга җавап бирелми, кулъязмалар, фотолар, рәсемнәр рецензияләнми, кире кайтарылмый. Редакциянең консультация бүлеге юк. Авторлар фикеренең редакциянеке белән туры килүе зарури түгел.*

*Реклама һәм игъланнарның эчтәлеге өчен реклама бирүчеләр җаваплы.*

"Кызыл таң"ның индексы:
атнага өч тапкыр басылганыныкы — П2760
атнага бер тапкыр — П3408
"Әллүки" журналы — П2712
"Тулпар" журналы — П2715

Безнең дәүләт банкы реквизитлары:
Издательство "Кызыл тан"
филиал ГУП РБ Издательский дом "Республика Башкортостан"
БАШКИРСКИЙ РФ АО "РОССЕЛЬХОЗБАНК"
р/с 40602810862000000102
к/с 30101810200000000934
БИК 048073934
ИНН 0278066967
КПП 027843006
ОКПО 31226910
ОКВЭД — 58.13.1
Дежур: Ф. ХӘБИБУЛЛИН.
© "Кызыл таң" № 103 (25407). 12+

*Сайлау-2019*

# Электоратны нәрсәләр кызыксындыра?

**Башкортстанның Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Илона Макаренко "туры элемтә"дә халык белән аралашты. Республиканың төрле почмакларыннан килгән сорауларда сайлауларда мөмкинлекләре чикле кешеләрнең катнашу мөмкинлеге, 8 сентябрьдә башка төбәкләрдә булучыларның ничек тавыш бирүе, кайсы очракта алдан тавыш биреп булуы һәм башка төрле яңалыклар турында сүз барды.**

**Шуларның иң әһәмиятлеләрен сезнең игътибарга да тәкъдим итәбез.**




Динар ЯЛАЛОВ,
Яңавыл шәһәре:

**— Бу сайлауларда да, элекке кебек, сайлаучы, имзасын куеп, бюллетень алып, аны кәрзиннәргә төшерәчәк. Ә нинди дер яңалыклар көтеләме?**

— Яңалыкларга килгәндә, КОИБларны әйтергә мөмкин. Бу сайлауларда республика буенча бюллетеньнәрне комплекслы эшкәртүче 225 корылма куелачак. Шулай ук, протоколда билгеләнгән кодлар да хата җибәрүгә юл куймаячак. 69 территориаль сайлау участогында һәм Уфаның һәр участогында диярлек видеокамералар эшләячәк. Бу сайлауларның үтәкүренмәле булуын тәэмин итәчәк. Шулай ук "мобиль сайлаучы" да әлеге сайлауларның үзенчәлеге булмакчы. Ягъни сайлаучылар, гариза язып, төрле җирдә тавыш бирә алачак. Мәскәүдә булган якташларыбыз өчен дә куанычлы хәбәр бар. Санлы сайлау участокларында гариза язып әлеге технология буенча тавыш бирергә мөмкин. Әмма бу республика Башлыгы вазыйфасына сайлауларга гына кагыла. Ә урындагы үзидарә органнарына сайлауларда алдан тавыш биреп булуын онытмагыз.

Валентина НИКОЛАЕВНА,
Уфа шәһәре:

**— Мин аягымны сындырдым. Участокка бара алмыйм. Ничек тавыш бирә алам?**

— Сезгә урындагы территориаль сайлау участогына гариза язарга кирәк. Яисә анда телефон аша шалтыратып, хәбәр итәргә кирәк. Сезгә, һичшиксез, ярдәм итәчәкләр.

Әхтәм КАЛИМОВ,
Күгәрчен районы:

**— Мин Себер якларында вахта ысулы белән эшлим. Сайлау көнендә Себердә булачакмын, әмма сайлауларда катнашасым килә. Миңа нишләргә?**

— Урындагы үзидарә органнарына сайлауларда алдан тавыш бирә алачаксыз. Ә республика Башлыгын сайлауларда, кызганычка каршы, катнаша алмаячаксыз.

Лилия ЛАТЫЙПОВА,
Учалы районы:

**— Өлкән яшьтәге әти-әнием өчен тавыш бирә аламмы?**

— Сайлауларда һәр граждан үзе тавыш бирергә тиеш. Әгәр дә бу мөмкин булмаса, территориаль сайлау участогына килә алмаулар турында хәбәр итегез, алар сезнең өйгә үзләре киләчәк. Алай гына да түгел, башка кеше өчен тавыш бирүгә юл куйган өчен участок комиссиясе әгъзалары административ җаваплылыкка тарттырыла. Бу законга каршы эш буларак санала.

Айрат Мидхәт улы,
Уфа шәһәре:

**— 8 сентябрьдә иртәнге 8дән кичке 8 сәгатькә кадәр эштә булачакмын. Ничек тавыш бирергә?**

— Быел сайлаулар иртәнге 7дән кичке 9га кадәр дәвам итәчәк. Шулай ук, сез, гариза язып, эш урынына якын булган участокта тавыш бирә аласыз.

*Шул ук вакытта...*

# "Антидебаты"ны күрми калмагыз!

**Республика тарихында беренче тапкыр! Башкортстан Башлыгы вазыйфасына барлык кандидатлар да бер мәйданчыкта, йөзгә-йөз карашып, туры эфирда! Чынлыкта кемнең кем булуын белербез! Сәяси ток-шоу "Антидебаты"ны күрми калмагыз!**



– "Дебатлар" сүзен мин беренче тапкыр әйткәч, Русия сәяси традициясенә тугры калып, аларга вакытны сарыф итәргә теләмим, дип җавап бирдем, — дип яза "Фейсбук"тагы битендә Башкортстан Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров. — Тик минә кешеләр белән даими аралашу тәҗрибәмнән чыгып, миңа аудитория белән турыдан-туры элемтәдә эшләү һәм мәгълүмат алу җиңелрәк дигән нәтиҗәгә килә башладым. Бу катнашучыларга да, тамашачыларга да файдалы булачак, шуңа күрә мин дебатларда да катнашам.

Дөресен генә әйткәндә, моны ничек эшләячәгемне күз алдыма да китермим, шуңа күрә китап сатып алдым, яхшы, диләр. Әзерләнәм. Ә кандидатларның штаблары һәм киңкүләм мәгълүмат чаралары датасын һәм вакытын билгеләр...

Дебатлар 5 сентябрьдә 19 сәгать 30 минутта БСТ, "Россия-1", "Россия-24", "Вся Уфа", РБК ТВ, UTV телеканалларында үтәчәк һәм YouTube, ВКонтакте, Facebook социаль челтәрләрендә трансляцияләнәчәк.

**Фәнүз ХӘБИБУЛЛИН.**

Сәлидә апа,
Әлшәй районы:

**— Кем өйдә тавыш бирергә хокуклы?**

— Сайлау участогына килә алмаучылар өйдә тавыш бирә ала. Ягъни инвалидлар, авырулар, авыруларны караучылар, яшь бала тәрбияләүче әниләр һәм башкалар. Әмма бу хакта сайлау участогына алдан хәбәр итәргә кирәк. Шуны да игътибарга аласы килә: "домашний арест"та булучылар, шулай ук, өйдә тавыш бирә.

Илгиз,
Мәләвез шәһәре:

**– Паспортымны алыштырырга биргән идем. Водитель таныклыгы яисә хәрби билет ярдәмендә тавыш бирә аламмы?**

– Паспортыгызны тапшырганда сезгә вакытлыча таныклык бирелгәндер, шуның белән тавыш бирергә хокуклысыз. Хәрби билет, Русия Федерациясенә керү турында сезнең бу ил кешесе булуны исбатлаучы документ белән дә сайлауларда катнаша аласыз. Ә менә водитель таныклыгы сезгә ярдәм итә алмаячак.

**Гөлия ГӘРӘЕВА язып алды.**